РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

САБИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
САТЫШЕВСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ

422070, Республика Татарстан, Сабинский район,
с. Сатышево, улЛенина , 17Б
тел. (84362) 2-24-16

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
САТЫШ АВЫЛ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422070, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Сатыш авылы, Ленин урам,17Б йорт
тел. (84362) 2-24-16

e-mail: Sat.sab@tatar.ru


ПОСТАНОВЛЕНИЕ
12.01.2026

КАРАР
№1

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Сатыш авыл җирлеге территориясендә терекөмешле лампаларны туплау урыннарын булдыру турында

РФ Хөкүмәтенең “Яктырту җайланмаларын, электр лампаларын тиешенчә җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, урыннан-урынга күчерү һәм урнаштыру гражданнарның гомеренә һәм сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерерүе мөмкин булган өлешендә, җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләрен раслау турында” 28.12.2020 елгы №2314 карарының 5 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге территориясендә терекөмешле лампаларны туплау урыннары булдырырга, шул исәптән мондый туплау урыннарын оештыру күпфатирлы йортларда туплау урыннарын оештыру өчен урыннар булмау сәбәпле мөмкин булмаган очракларда, түбәндәге адрес буенча:

- Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Сатыш авылы, Совет ур., 24, 20 нче бина.

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге территориясендә терекөмешле лампалар туплану урыннарының урнашуы турында әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасында мондый урыннарның урнашуы турында мәгълүмат урнаштыру юлы белән, шулай ук мәгълүматны җирлекнең рәсми сайтында, җирлекнең түбәндәге адреслар буенча урнаштырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән кулланучыларга хәбәр итәргә: ТР, Саба районы, Сатыш авылы, Ленин ур., 17Б; Аккүл Бигәнәй авылы, М.Җәлил ур.,24 ; Мамалай авылы, Чапай ур., 6.

3. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл башкарма комитетының «Терекөмешле лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру урыннарын раслау турында» 06.02.2014 елгы № 7карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, җирлекнең рәсми сайтында

http://saby.tatarstan.ru/satish, шулай ук түбәндәге адреслар буенча урнаштырылган мәгълүмат стендларында: ТР, Саба районы, Сатыш авылы, Ленин ур., 17Б; Аккүл Бигәнәй авылы, М.Җәлил ур.,24 ; Мамалай авылы, Чапай ур., 6 рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Сатыш авыл җирлеге башлыгы Ф.Ф.Шафигуллин